Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге Советының кырыгынчы утырышы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

19 ноябрь, 2024 ел № 131

Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлегенең Званка авылы территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җыенны билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге уставының 23 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кощаково авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 62 номерлы (2021 елның 25 декабрендәге 37 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Кощаково авыл җирлеге Советы карары нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге Советы карар кабул итте:**

1. Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлегенең Званка авылы территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җыен билгеләргә.

Чокыр урамы гражданнар җыенын 2024 елның 30 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Чокыр урамы киселешендә уздырырга.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда Кощаково авыл җирлеге Званка авылының Чокыр урамында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 8000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә (Чокыр ур.) гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Кощаково авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Кощаково авыл җирлеге башлыгы З.Н. Саттарова